**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7863**
**03.12.2021**

Башкарма комитетның 2019 елның 31 октябрендәге 5597 номерлы карары белән расланган 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органнарының гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм күрсәтү һәм социаль ярдәм күрсәтү хокукын тормышка ашыру турында» 2009 елның 9 апрелендәге 40/17 номерлы карары, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2019 елның 31 октябрендәге 5597 номерлы карары (Башкарма комитетның 2020 елның 6 апрелендәге 1695 номерлы, 2020 елның 12 октябрендәге 5229 номерлы, 2020 елның 25 декабрендәге 7278 номерлы, 2021 елның 31 мартындагы 2191 номерлы, 2021 елның 21 июнендәге 4177 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасына, 6 бүлектәге 2 бурычның 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 13. | Бөек Ватан сугышы ветераннарын, хәрби бәрелешләр ветераннарын, төзүче-ветераннарны календарь бәйрәмнәр (23 февраль, 8 Март, 9 Май) белән, шәһәр һәм республика үсешенә зур өлеш керткән юбилярларны (85, 90, 95, 100 яшь һәм өлкәнрәк) котлау | Башкарма комитет | Ел дәвамында | Кеше саны | 0 | 300 | 300 | 300 | 585,92 | 565,97 | 643,97 |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында рәсми бастырып чыгаруны, «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов